ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 8 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» 2002 елның 15 октябрендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең беренче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 10; 2003, № 9 (II өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 20 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), «дүрт елга» сүзләрен «алты елга» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. «Россия Федерациясендә судьялар бергәлеге органнары турында» Федераль законның 6 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 2 маендагы 122-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре вәкаләтләре, күрсәтелгән Федераль закон үз көченә кергән көнгә аларның срогы тәмамланмаган булса, ике елга озайтыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 19 июнь
№ 37-ТРЗ